Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Кече Колбай-Мораса авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2019 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Кече Колбай-Мораса авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Кече Колбай-Мораса авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр башкару.

Халык җыены рәисе: Г.Ф. Сафина

Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Г.Ф. Сафина